**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Сарлы авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Сарлы авылы № 73-37 24 ноябрь 2017 ел

«Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының» Сарлы авыл җирлеге»муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында"Азнакай муниципаль районы авыл җирлеге Сарлы Советы карары проекты

Җирле үзидарә турында федераль һәм республика законнарындагы үзгәрешләргә бәйле рәвештә

Сарлы авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Сарлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сарлы авыл Советы Карары проектын (1 нче кушымта) кабул итәргә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында түбәндәге веб-адрес буенча урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә: http://pravo.tatarstan.ru, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча: http:// aznakayevo.tatarstan.ru, Сарлы авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

3. «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Сарлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» Сарлы авыл Советы карары проекты буенча 18.12.2017 елда 16.00 сәгатьтә түбәндәге адрес буенча ачык тыңлаулар үткәрергә: Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы, Сарлы авылы, Үзәк урам, 68А йорт.

4. «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Сарлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карар проекты буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр, гавами тыңлауларда катнашуга гаризалар түбәндәге адрес буенча бирелергә мөмкин: Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы, Сарлы авылы, Үзәк урам, 68А йорт.

5. Гавами тыңлаулар уздыру буенча составта эшче төркем төзергә:

- М. Р. Шәрипов – Сарлы авыл җирлеге башлыгы;
- А. Т.Кадыйров – Сарлы авыл җирлеге депутаты;
- Д.Н. Миңнеханов – Сарлы авыл җирлеге депутаты.

6. Гавами тыңлаулар үткәрү буенча эшче төркемгә «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Сарлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында»карар проекты буенча гавами тыңлаулар үткәрүне, гражданнарның тәкъдимнәрен кабул итүне, исәпкә алуны тәэмин итәргә.

7. Законлылык һәм хокук тәртибе мәсьәләләре буенча даими комиссиягә гавами тыңлауларда әйтелгән һәм фикер алышу барышында кергән тәкъдимнәрне исәпкә алып, карар проектын эшләп бетерергә һәм чираттагы утырышка карауга кертергә.

8. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис М.Р.Шәрипов